**ЗАКОН**
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

# О внесении изменений в Бюджетный кодекс Республики Татарстан и приостановлении действия отдельных положений Бюджетного кодекса Республики Татарстан

Принят
Государственным Советом
Республики Татарстан
23 сентября 2021 года

**Статья 1**

Внести в Бюджетный кодекс Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, №11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 79 (часть I); 2020, № 51 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 94 (часть I); 2021, № 20 (часть I) следующие изменения:

1) абзац второй пункта 2 статьи 24 изложить в следующей редакции:

«В случае утверждения законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан в составе источников финансирования дефицита бюджета Республики Татарстан поступлений от продажи акций и иных форм участия в капитале, от реализации государственных запасов драгоценных металлов и драгоценных камней, находящихся в собственности Республики Татарстан, а также бюджетных кредитов, предоставляемых из федерального бюджета бюджету Республики Татарстан на финансовое обеспечение реализации инфраструктурных проектов, и (или) снижения остатков средств на счетах по учету средств бюджета Республики Татарстан, в том числе средств Резервного фонда Республики Татарстан, разницы между средствами, получаемыми от возврата средств с банковских депозитов, и средствами, размещаемыми на банковских депозитах, дефицит бюджета Республики Татарстан может превысить ограничения, установленные настоящим пунктом, в пределах суммы указанных поступлений, снижения остатков средств на счетах по учету средств бюджета

Республики Татарстан, в том числе средств Резервного фонда Республики Татарстан, в пределах положительной разницы между средствами, получаемыми от возврата средств с банковских депозитов, и средствами, размещаемыми на банковских депозитах, а также в пределах объема бюджетных ассигнований, направленных на финансовое обеспечение реализации инфраструктурных проектов, источником финансового обеспечения которых являются бюджетные кредиты, предоставляемые из федерального бюджета бюджету Республики Татарстан на финансовое обеспечение реализации инфраструктурных проектов.»;

2) абзац четвертый пункта 3 статьи 25 изложить в следующей редакции:

«в объеме, не превышающем сумму остатка неиспользованных бюджетных ассигнований на оплату заключенных от имени Республики Татарстан государственных контрактов на поставку товаров, выполнение работ, оказание услуг, подлежавших в соответствии с условиями этих государственных контрактов оплате в отчетном финансовом году, бюджетных ассигнований на предоставление из бюджета Республики Татарстан бюджетам бюджетной системы Российской Федерации субсидий, субвенций и иных межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, предоставление которых в отчетном финансовом году осуществлялось в пределах суммы, необходимой для оплаты денежных обязательств получателей средств бюджета бюджетной системы Российской Федерации, источником финансового обеспечения которых являлись указанные межбюджетные трансферты, бюджетных ассигнований на предоставление субсидий юридическим лицам, предоставление которых в отчетном финансовом году осуществлялось в пределах суммы, необходимой для оплаты денежных обязательств получателей субсидий, источником финансового обеспечения которых являлись указанные субсидии, в случаях, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан, направляются на увеличение соответствующих бюджетных ассигнований на указанные цели;»;

3) в статье 37:

а) пункт 11 изложить в следующей редакции:

«11. Государственная гарантия Республики Татарстан (муниципальная гарантия), обеспечивающая исполнение обязательств принципала по кредиту (займу, в том числе облигационному), подлежит отзыву гарантом только в следующих случаях:

1) изменение без предварительного письменного согласия гаранта указанных в государственной гарантии Республики Татарстан (муниципальной гарантии) условий основного обязательства, которые не могут быть изменены без предварительного письменного согласия гаранта;

2) нецелевое использование средств кредита (займа, в том числе облигационного), обеспеченного государственной гарантией Республики Татарстан (муниципальной гарантией).»;

б) пункт 27 дополнить предложением следующего содержания: «Государственная гарантия Республики Татарстан (муниципальная гарантия),

обеспечивающая исполнение обязательств принципала по кредиту (займу, за исключением облигационного), предоставляется при условии установления в кредитном договоре (договоре займа) и (или) договоре о предоставлении указанной государственной гарантии Республики Татарстан (муниципальной гарантии) обязательств кредитора (займодавца) осуществлять со своей стороны контроль за целевым использованием средств указанного кредита (займа).»;

4) абзац четвертый статьи 43 дополнить словами «, субвенций бюджетам федеральных территорий в случаях, установленных федеральными законами, для реализации передаваемых органам публичной власти федеральных территорий полномочий органов государственной власти Республики Татарстан»;

5) в статье $44^4$:

а) абзац седьмой пункта 3 после слов «Кабинета Министров Республики Татарстан,» дополнить словами «субсидий, предоставление которых обусловлено увеличением бюджетных ассигнований в соответствии с абзацем четвертым пункта 3 статьи 25 настоящего Кодекса,»;

б) в пункте 4:

дополнить новым абзацем вторым следующего содержания:

«Повторное распределение между муниципальными образованиями субсидий, предоставление которых было осуществлено в отчетном финансовом году и в текущем финансовом году обусловлено увеличением бюджетных ассигнований в соответствии с абзацем четвертым пункта 3 статьи 25 настоящего Кодекса, не осуществляется.»;

абзацы второй – четвертый считать соответственно абзацами третьим – пятым;

в) пункт $4^1$ дополнить абзацами следующего содержания:

«Заключение соглашений о предоставлении из бюджета Республики Татарстан субсидий местным бюджетам, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период, осуществляется до 15 февраля очередного финансового года, за исключением соглашений о предоставлении субсидий, бюджетные ассигнования на предоставление которых предусмотрены в соответствии с законом Республики Татарстан о внесении изменений в закон Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан и которые заключаются не позднее 30 дней после дня вступления в силу указанного закона Республики Татарстан.

Соглашение о предоставлении субсидии заключается на срок, который не может быть менее срока, на который в установленном порядке утверждено распределение субсидий между муниципальными образованиями.

В случае нарушения сроков, предусмотренных абзацем вторым настоящего пункта, бюджетные ассигнования бюджета Республики Татарстан, предусмотренные на текущий финансовый год на соответствующие цели, направляются на увеличение бюджетных ассигнований резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан для оказания финансовой помощи

местным бюджетам в размере субсидии, в отношении которой не заключено соглашение о ее предоставлении из бюджета Республики Татарстан, в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

6) в статье $44^5$:

а) пункт 1 изложить в следующей редакции:

«1. Иные межбюджетные трансферты из бюджета Республики Татарстан предоставляются местным бюджетам на основании законов Республики Татарстан и принимаемых в соответствии с ними иных нормативных правовых актов органов государственной власти Республики Татарстан на финансовое обеспечение расходных обязательств муниципальных образований:

1) в случае софинансирования, в том числе в полном объеме, расходных обязательств, возникающих при выполнении полномочий органов местного самоуправления, не урегулированных федеральными законами и (или) законами Республики Татарстан;

2) в случае софинансирования, в том числе в полном объеме, расходных обязательств, возникающих при выполнении полномочий органов местного самоуправления по решению вопросов местного значения;

3) в случае предоставления бюджетных ассигнований, источником финансового обеспечения которых являются резервные фонды Президента Российской Федерации и Правительства Российской Федерации, а также резервный фонд Кабинета Министров Республики Татарстан;

4) в случаях, установленных законами Республики Татарстан (за исключением закона Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период и закона Республики Татарстан о внесении изменений в закон Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на текущий финансовый год и плановый период);

5) в случаях, установленных нормативными правовыми актами Кабинета Министров Республики Татарстан.»;

б) пункт 4 изложить в следующей редакции:

«4. Распределение иных межбюджетных трансфертов местным бюджетам, предоставляемых из бюджета Республики Татарстан, между муниципальными образованиями утверждается законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период и (или) принятыми в соответствии с ним до 15 февраля очередного финансового года нормативными правовыми актами Кабинета Министров Республики Татарстан, за исключением иных межбюджетных трансфертов:

1) источником финансового обеспечения которых являются бюджетные ассигнования резервных фондов Президента Российской Федерации и Правительства Российской Федерации, а также резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан;

2) предоставление которых осуществляется за счет иным образом зарезервированных в бюджете Республики Татарстан бюджетных ассигнований,

которые подлежат распределению актами Кабинета Министров Республики Татарстан до 1 октября текущего финансового года;

3) предоставление которых осуществляется за счет бюджетных ассигнований, предусмотренных в соответствии с законом Республики Татарстан о внесении изменений в закон Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан, и которые подлежат распределению актами Кабинета Министров Республики Татарстан не позднее 30 дней после дня вступления в силу указанного закона Республики Татарстан;

4) предоставляемых в целях поощрения муниципальных образований, в том числе за достижение наилучших значений показателей социально-экономического развития и (или) лучшие практики деятельности органов местного самоуправления;

5) предоставляемых на возмещение фактически осуществленных расходов местных бюджетов;

6) объемы которых обусловлены поступлением доходов федерального бюджета и (или) бюджета Республики Татарстан;

7) распределяемых на конкурсной основе.»;

в) дополнить пунктами $4^1$ и $4^2$ следующего содержания:

«$4^1$. Повторное распределение между муниципальными образованиями иных межбюджетных трансфертов, предоставление которых было осуществлено в отчетном финансовом году и в текущем финансовом году обусловлено увеличением бюджетных ассигнований в соответствии с абзацем четвертым пункта 3 статьи 25 настоящего Кодекса, не осуществляется.

При этом допускается утверждение не распределенного между муниципальными образованиями объема иных межбюджетных трансфертов в размере не более 5 процентов общего объема соответствующего иного межбюджетного трансферта, утвержденного на первый год планового периода, и не более 10 процентов общего объема указанного иного межбюджетного трансферта, утвержденного на второй год планового периода.

$4^2$. Если нормативными правовыми актами Кабинета Министров Республики Татарстан, устанавливающими порядок (правила) предоставления из бюджета Республики Татарстан иных межбюджетных трансфертов местным бюджетам, предусмотренных законом Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан на очередной финансовый год и плановый период, предусмотрено заключение соглашения о предоставлении иного межбюджетного трансферта, такие соглашения заключаются до 15 февраля очередного финансового года, за исключением соглашений о предоставлении иных межбюджетных трансфертов, бюджетные ассигнования на предоставление которых предусмотрены в соответствии с законом Республики Татарстан о внесении изменений в закон Республики Татарстан о бюджете Республики Татарстан и которые заключаются не позднее 30 дней после дня вступления в силу указанного закона Республики Татарстан.

Соглашения о предоставлении иных межбюджетных трансфертов из бюджета Республики Татарстан местным бюджетам и дополнительные

соглашения к указанным соглашениям, предусматривающие внесение в них изменений или их расторжение, заключаются в соответствии с типовыми формами, утверждаемыми Министерством финансов Республики Татарстан.

Соглашение о предоставлении иного межбюджетного трансферта заключается на срок, который не может быть менее срока, на который в установленном порядке утверждено распределение иных межбюджетных трансфертов между муниципальными образованиями.

В случае нарушения сроков, предусмотренных абзацем первым настоящего пункта, бюджетные ассигнования бюджета Республики Татарстан, предусмотренные на текущий финансовый год на соответствующие цели, направляются на увеличение бюджетных ассигнований резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан для оказания финансовой помощи местным бюджетам в размере иного межбюджетного трансферта, в отношении которого не заключено соглашение о его предоставлении из бюджета Республики Татарстан, в порядке, установленном Кабинетом Министров Республики Татарстан.»;

7) в статье $44^6$:

а) в пункте 10:

дополнить новым абзацем вторым следующего содержания:

«Повторное распределение между муниципальными образованиями субвенций, предоставление которых было осуществлено в отчетном финансовом году и в текущем финансовом году обусловлено увеличением бюджетных ассигнований в соответствии с абзацем четвертым пункта 3 статьи 25 настоящего Кодекса, не осуществляется.»;

абзацы второй – четвертый считать соответственно абзацами третьим – пятым;

б) дополнить пунктом 12 следующего содержания:

«12. Положения настоящей статьи применяются при предоставлении субвенций из бюджета Республики Татарстан бюджетам федеральных территорий в целях финансового обеспечения расходных обязательств федеральных территорий, возникающих при выполнении государственных полномочий Республики Татарстан, переданных для осуществления федеральным территориям в случаях, установленных федеральными законами.»;

8) пункт 2 статьи 53 дополнить подпунктом $1^1$ следующего содержания:

«$1^1$) документах, определяющих цели национального развития Российской Федерации и направления деятельности органов публичной власти по их достижению;»;

9) в статье $60^1$:

а) подпункты 1 и 2 пункта 3 признать утратившими силу;

б) подпункты 4 и 5 пункта $3^1$ признать утратившими силу;

10) в статье 77:

а) в пункте 3:

абзац восьмой после слов «имеющих целевое назначение,» дополнить словами «предоставления из федерального бюджета бюджету Республики Татарстан бюджетного кредита на финансовое обеспечение реализации инфраструктурных проектов»;

абзац десятый после слов «отчетном финансовом году,» дополнить словами «в том числе на сумму неисполненного казначейского обеспечения обязательств, выданного в соответствии со статьей $242^{22}$ Бюджетного кодекса Российской Федерации,»;

в абзаце пятнадцатом слова «восьмым и десятым» заменить словами «восьмым, десятым и одиннадцатым»;

б) в пункте $3^2$:

дополнить новым абзацем восьмым следующего содержания:

«в случае увеличения бюджетных ассигнований резервного фонда Кабинета Министров Республики Татарстан на основании решений Кабинета Министров Республики Татарстан, а также бюджетных ассигнований на предоставление из бюджета Республики Татарстан межбюджетных трансфертов, имеющих целевое назначение, в соответствии с пунктом $4^1$ статьи $44^4$ и пунктом $4^2$ статьи $44^5$ настоящего Кодекса.»;

абзац восьмой считать абзацем девятым;

11) в пункте 4 статьи $93^1$ слова «юридических лиц, не являющихся участниками бюджетного процесса, бюджетными и автономными учреждениями» заменить словами «получателей средств из бюджета и казначейских счетах для осуществления и отражения операций с денежными средствами участников казначейского сопровождения»;

12) в статье $97^1$:

а) наименование после слова «Составление» дополнить словами «, представление и утверждение»;

б) в абзаце первом пункта 5 слова «(далее – главные администраторы бюджетных средств)» исключить;

13) пункт 4 статьи $97^2$ дополнить абзацем следующего содержания:

«Министерство финансов Республики Татарстан представляет бюджетную отчетность об исполнении консолидированного бюджета Республики Татарстан и бюджета Территориального фонда обязательного медицинского страхования Республики Татарстан (за исключением отчетности, содержащей сведения, отнесенные к государственной тайне либо носящие конфиденциальный характер), подписанную усиленной квалифицированной электронной подписью министра финансов Республики Татарстан (уполномоченного должностного лица), в государственной интегрированной информационной системе управления общественными финансами «Электронный бюджет».».

**Статья 2**

Приостановить до 1 января 2022 года действие статьи $53^{1}$, абзаца шестнадцатого пункта 3 статьи 77 (в части уменьшения бюджетных ассигнований, предусмотренных на обслуживание государственного долга) Бюджетного кодекса Республики Татарстан (Ведомости Государственного Совета Татарстана, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II часть), № 10 (I часть), № 12 (IV часть); 2006, № 6 (I часть), № 12 (I часть); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III часть), № 10 (I часть); 2009, № 7 – 8 (I часть), № 12 (I часть); 2010, № 7 (II часть), № 12 (I часть); 2011, № 8 (I часть), № 11 (I часть), № 11 (II часть); 2012, № 11 (I часть); 2013, № 7, № 10, № 11 (I часть); 2014, № 5, № 12 (III часть); 2015, № 7 (I часть), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III часть), № 9 (II часть); Собрание законодательства Республики Татарстан, 2017, № 1 (часть I), № 76 (часть I); 2018, № 22 (часть I), № 78 (часть I); 2019, № 2 (часть I), № 19 (часть I), № 79 (часть I); 2020, № 51 (часть I), № 57 (часть I), № 77 (часть I), № 94 (часть I); 2021, № 20 (часть I).

**Статья 3**

1. Настоящий Закон вступает в силу со дня его официального опубликования, за исключением положений, для которых настоящей статьей предусмотрены иные сроки вступления их в силу.

2. Пункт 8, абзацы третий и четвертый подпункта «а» пункта 10, пункт 11, подпункт «а» пункта 12, пункт 13 статьи 1 настоящего Закона вступают в силу с 1 января 2022 года.

3. Положения статей $44^{4}$, $44^{5}$, $44^{6}$, $60^{1}$ Бюджетного кодекса Республики Татарстан (в редакции настоящего Закона) применяются к правоотношениям, возникающим при составлении и исполнении бюджетов бюджетной системы Республики Татарстан, начиная с бюджетов на 2022 год и на плановый период 2023 и 2024 годов.

Президент
Республики Татарстан — Р.Н. Минниханов

Казань, Кремль
30 сентября 2021 года
№ 65-ЗРТ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# Татарстан Республикасы Бюджет кодексына үзгәрешләр кертү һәм Татарстан Республикасы Бюджет кодексы аерым нигезләмәләренең гамәлдә булуын туктатып тору турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2021 елның 23 сентябрендә
кабул ителде

**1 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 24 статьяның 2 пунктындагы икенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы белән Татарстан Республикасы бюджет кытлыгын финанслау чыганаклары составында Татарстан Республикасы милкендәге акцияләрне һәм капиталда катнашуның бүтән рәвешләрен сатудан, кыйммәтле металларның һәм кыйммәтле ташларның дәүләт запасларын реализацияләүдән керемнәр, шулай ук инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджет кредитлары һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар, шул исәптән Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары, кимү, банк депозитларыннан акчаларны кире кайтарудан алына торган акчалар һәм банк депозитларына урнаштырыла торган акчалар арасындагы

аерма расланган очракта, Татарстан Республикасы бюджеты кытлыгы әлеге пунктта билгеләнгән чикләүләрдән күрсәтелгән керемнәр суммасы, Татарстан Республикасы бюджеты акчаларын исәпкә алу счетларында калган акчалар, шул исәптән Татарстан Республикасының Резерв фонды акчалары кимү чикләрендә, банк депозитларыннан акчаларны кире кайтарудан алына торган акчалар һәм банк депозитларына урнаштырыла торган акчалар арасындагы уңай аерма чикләрендә, шулай ук финанс белән тәэмин итү чыганагын инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган бюджет кредитлары тәшкил иткән инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә юнәлтелгән бюджет ассигнованиеләре күләме чикләрендә артыграк булырга мөмкин.»;

2) 25 статьяның 3 пунктындагы дүртенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган очракларда, товарлар ташуга, эшләр башкаруга, хезмәтләр күрсәтүгә Татарстан Республикасы исеменнән төзелгән дәүләт контрактлары шартлары нигезендә хисап финанс елында түләнергә тиешле бу дәүләт контрактларын түләүгә бюджет ассигнованиеләренең, максатчан билгеләнешле бюджетара трансфертлар финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчаларын алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә хисап финанс елында бирелгән максатчан билгеләнешле субсидияләрне, субвенцияләрне һәм башка бюджетара трансфертларны Татарстан Республикасы бюджетыннан Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына бирүгә бюджет ассигнованиеләренең, субсидияләр финанс белән тәэмин итү чыганагы булып торган субсидияләр алучыларның акчалата йөкләмәләрен түләү өчен кирәкле сумма чикләрендә хисап финанс елында бирелгән күрсәтелгән субсидияләрне юридик затларга бирүгә бюджет ассигнованиеләренең файдаланылмый калган суммасыннан артмый торган күләмдә күрсәтелгән максатларга тиешле бюджет ассигнованиеләрен арттыру өчен җибәреләләр;»;

3) 37 статьяда:

а) 11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«11. Принципалның кредит (заем, шул исәптән облигацияле заем) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) гарант тарафыннан түбәндәге очракларда гына кире алынырга тиеш:

1) төп йөкләмәнең Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясендә (муниципаль гарантиядә) күрсәтелгән, гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка үзгәртелә алмый торган шартлары гарантның алдан бирелгән язма ризалыгыннан башка үзгәртелгәндә;

2) Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) белән тәэмин ителгән кредит (заем, шул исәптән облигацияле заем) акчалары максатчан файдаланылмаганда.»;

б) 27 пунктка түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Принципалның кредит (заем, облигацияле заемнан тыш) буенча йөкләмәләрен үтәүне тәэмин итә торган Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясе (муниципаль гарантия) кредиторның (заем бирүченең) күрсәтелгән кредит (заем) акчаларының максатчан файдаланылуын тикшереп торуны үзе тарафыннан башкару бурычлары кредит шартнамәсендә (заем шартнамәсендә) һәм (яисә) күрсәтелгән Татарстан Республикасы дәүләт гарантиясен (муниципаль гарантияне) бирү турындагы шартнамәдә билгеләнгән булса бирелә.»;

4) 43 статьяның дүртенче абзацына «, федераль законнарда билгеләнгән очракларда, федераль территорияләрнең гавами хакимияте органнарына тапшырыла торган Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль территорияләр бюджетларына субвенцияләр»;

5) $44^4$ статьяда:

а) 3 пунктның җиденче абзацында «субсидияләр бирү,» сүзләрен «субсидияләр,» сүзенә алмаштырырга, «субсидияләрдән тыш,» сүзләреннән соң «әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле рәвештә бирелә торган субсидияләр бирү» сүзләрен өстәргә;

б) 4 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле рәвештә хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында бирелгән субсидияләрне муниципаль берәмлекләр арасында кабат бүлү башкарылмый.»;

икенче – дүртенче абзацларны тиешенчә өченче – бишенче абзацлар дип санарга;

в) $4^1$ пунктка түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган субсидияләрне бирү турында килешүләр төзү чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр башкарыла, моңа Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы нигезендә бюджет ассигнованиеләре бирү каралган һәм күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча төзелә торган субсидияләр бирү турындагы килешүләр керми.

Субсидия биру турында килешү муниципаль берәмлекләр арасында субсидияләр бүлү билгеләнгән тәртиптә расланган сроктан ким була алмаган срокка төзелә.

Әлеге пунктның икенче абзацында каралган сроклар бозылган очракта, агымдагы финанс елына тиешле максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга биру турында килешү төзелмәгән субсидия күләмендә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.»;

б) $44^5$ статьяда:

а) 1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертлар Татарстан Республикасы законнары һәм Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының аларга ярашлы рәвештә кабул ителә торган бүтән норматив хокукый актлары нигезендә муниципаль берәмлекләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итүгә түбәндәге очракларда бирелә:

1) җирле үзидарә органнарының федераль законнар һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнары белән җайга салынмаган вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу, шул исәптән тулы күләмдә, очрагында;

2) җирле үзидарә органнарының җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу, шул исәптән тулы күләмдә, очрагында;

3) финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президентының һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең резерв фондлары, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фонды булган бюджет ассигнованиеләрен биру очрагында;

4) Татарстан Республикасы законнарында (чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законыннан һәм агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законыннан тыш) билгеләнгән очракларда;

5) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының норматив хокукый актларында билгеләнгән очракларда.»;

б) 4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«4. Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирелә торган башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында бүлү чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законы һәм (яисә) аның нигезендә чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр кабул ителгән Татарстан Республикасы

Министрлар Кабинеты норматив хокукый актлары белән раслана, моңа түбәндәге башка бюджетара трансфертлар керми:

1) финанс белән тәэмин итү чыганагы Россия Федерациясе Президенты һәм Россия Федерациясе Хөкүмәте резерв фондларының, шулай ук Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре булган;

2) Татарстан Республикасы бюджетында башкача резервланган, агымдагы финанс елының 1 октябренә кадәр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән бүленергә тиешле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән бирелә торган;

3) Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы нигезендә каралган һәм күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты актлары белән бүленергә тиешле бюджет ассигнованиеләре исәбеннән бирелә торган;

4) муниципаль берәмлекләрне бүләкләү максатларында, шул исәптән социаль-икътисадый үсешнең иң яхшы күрсәткечләренә ирешкән өчен һәм (яисә) җирле үзидарә органнары эшчәнлегендәге яхшы тәҗрибәләр өчен бирелә торган;

5) җирле бюджетларның фактта тотылган чыгымнарын каплауга бирелә торган;

6) күләмнәре федераль бюджеттан һәм (яисә) Татарстан Республикасы бюджетыннан керемнәр алынуга бәйле булган;

7) конкурс нигезендә бүленә торган.»;

в) түбәндәге эчтәлекле $4^1$ һәм $4^2$ пунктлар өстәргә:

«$4^1$. Әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле рәвештә хисап финанс елында һәм агымдагы финанс елында бирелгән башка бюджетара трансфертларны муниципаль берәмлекләр арасында кабат бүлү башкарылмый.

Бу вакытта муниципаль берәмлекләр арасында бүленмәгән башка бюджетара трансфертларның күләмен план чорының беренче елына расланган тиешле башка бюджетара трансфертның гомуми күләменнән 5 процентыннан артмаган күләмдә һәм план чорының икенче елына расланган күрсәтелгән башка бюджетара трансфертның гомуми күләменнән 10 процентыннан артмаган күләмдә раслау рөхсәт ителә.

$4^2$. Әгәр Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга чираттагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законында каралган башка бюджетара трансфертларны бирү тәртибен (кагыйдәләрен) билгели торган Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый актларында башка бюджетара трансферт бирү турында килешү төзү каралган булса, мондый килешүләр чираттагы финанс елының 15 февраленә кадәр төзелә, моңа Татарстан Республикасы бюджеты турында Татарстан Республикасы законына үзгәрешләр кертү хакында Татарстан Республикасы законы нигезендә бюджет

ассигнованиеләре бирү каралган һәм күрсәтелгән Татарстан Республикасы законы үз көченә кергән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча төзелә торган башка бюджетара трансфертлар бирү турындагы килешүләр керми.

Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга башка бюджетара трансфертлар бирү турында килешүләр һәм күрсәтелгән килешүләргә үзгәрешләр кертүне яисә аларны өзүне күздә тоткан аларга өстәмә килешүләр Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы тарафыннан раслана торган типлаштырылган формалар нигезендә төзелә.

Башка бюджетара трансферт бирү турында килешү муниципаль берәмлекләр арасында башка бюджетара трансфертларны бүлү билгеләнгән тәртиптә расланган сроктан ким була алмаган срокка төзелә.

Әлеге пунктның беренче абзацында каралган сроклар бозылган очракта, агымдагы финанс елына тиешле максатларга каралган Татарстан Республикасы бюджеты бюджет ассигнованиеләре Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты билгеләгән тәртиптә Татарстан Республикасы бюджетыннан җирле бюджетларга бирү турында килешү төзелмәгән башка бюджетара трансферт күләмендә финанс ярдәме күрсәтү өчен Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләрен арттыруга җибәрелә.»;

7) $44^6$ статьяда:

а) 10 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа икенче абзац өстәргә:

«Хисап финанс елында бирелгән һәм агымдагы финанс елында бирелүе әлеге Кодексның 25 статьясындагы 3 пунктының дүртенче абзацы нигезендә бюджет ассигнованиеләре артуга бәйле булган субвенцияләрне муниципаль берәмлекләр арасында кабат бүлү башкарылмый.»;

икенче – дүртенче абзацларны тиешенчә өченче – бишенче абзацлар дип санарга;

б) түбәндәге эчтәлекле 12 пункт өстәргә:

«12. Әлеге статья нигезләмәләре, федераль законнарда билгеләнгән очракларда, федераль территорияләр тарафыннан гамәлгә ашырылуы өчен тапшырылган Татарстан Республикасы дәүләт вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган федераль территорияләрнең чыгым йөкләмәләрен финанс белән тәэмин итү максатларында Татарстан Республикасы бюджетыннан федераль территорияләр бюджетларына субвенцияләр биргәндә кулланыла.»;

8) 53 статьяның 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле $1^1$ пунктча өстәргә:

«$1^1$) Россия Федерациясенең илкүләм үсеше максатларын һәм аларга ирешү буенча гавами хакимият органнары эшчәнлеге юнәлешләрен билгели торган документларга;»;

9) $60^1$ статьяда:

а) 3 пунктның 1 һәм 2 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

б) $3^1$ пунктның 4 һәм 5 пунктчаларын үз көчләрен югалткан дип танырга;

10) 77 статьяда:

а) 3 пунктта:

сигезенче абзацта «хәбәрнамә алынган,» сүзләреннән соң «инфраструктура проектларын гамәлгә ашыруны финанс белән тәэмин итүгә федераль бюджеттан Татарстан Республикасы бюджетына бюджет кредиты бирелгән,» сүзләрен өстәргә;

унынчы абзацта «арттырган очракта» сүзләреннән соң «, шул исәптән Россия Федерациясе Бюджет кодексының $242^{22}$ статьясы нигезендә бирелгән йөкләмәләрне үтәлмәгән казнадан тәэмин итү суммасына» сүзләрен өстәргә;

унбишенче абзацта «сигезенче һәм унынчы» сүзләрен «сигезенче, унынчы һәм унберенче» сүзләренә алмаштырырга;

б) $3^{2}$ пунктта:

түбәндәге эчтәлекле яңа сигезенче абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары нигезендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты резерв фондының бюджет ассигнованиеләре, шулай ук әлеге Кодексның $44^{4}$ статьясындагы $4^{1}$ пункты һәм $44^{5}$ статьясындагы $4^{2}$ пункты нигезендә Татарстан Республикасы бюджетыннан максатчан билгеләнеше булган бюджетара трансфертлар бирүгә бюджет ассигнованиеләре арттырылган очракта.»;

сигезенче абзацны тугызынчы абзац дип санарга;

11) $93^{1}$ статьяның 4 пунктында «бюджет процессында катнашучы булып тормаган, бюджет учреждениеләре һәм автоном учреждениеләр булмаган юридик затларның» сүзләрен «бюджеттан акчалар алучыларның акчалары белән операцияләрне гамәлгә ашыру һәм чагылдыру өчен казначылык счетларындагы һәм казначылык аша эшли торган катнашучыларның» сүзләренә алмаштырырга;

12) $97^{1}$ статьяда:

а) исемендә «төзү» сүзеннән соң «, тапшыру һәм раслау» сүзләрен өстәргә;

б) 5 пунктның беренче абзацында «(алга таба – бюджет акчаларының баш администраторлары)» сүзләрен төшереп калдырырга;

13) $97^{2}$ статьяның 4 пунктына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы «Электрон бюджет» җәмәгать финанслары белән идарә итүнең дәүләт интеграцияләнгән мәгълүмат системасында Татарстан Республикасы финанс министрының (вәкаләтле вазыйфаи затның) көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган Татарстан Республикасының берләштерелгән бюджеты һәм Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты үтәлеше турында бюджет хисаплылыгын (дәүләт серенә кертелгән йә конфиденциаль характердагы белешмәләрне үз эченә алган хисаплардан тыш) тапшыра.».

**2 статья**

Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $53^{1}$ статьясының, 77 статьясының 3 пунктындагы уналтынчы абзацының (дәүләт бурычына хезмәт күрсәтү өчен каралган бюджет ассигнованиеләрен киметү өлешендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2004, № 4 – 5; 2005, № 6 (II өлеш), № 10 (I өлеш), № 12 (IV өлеш); 2006, № 6 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2007, № 8, № 10; 2008, № 8 (III өлеш), № 10 (I өлеш); 2009, № 7 – 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2010, № 7 (II өлеш), № 12 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 11 (I өлеш), № 11 (II өлеш); 2012, № 11 (I өлеш); 2013, № 7, № 10, № 11 (I өлеш); 2014, № 5, № 12 (III өлеш); 2015, № 7 (I өлеш), № 8 – 9; 2016, № 3, № 6 (III өлеш), № 9 (II өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 1 (I өлеш), № 76 (I өлеш); 2018, № 22 (I өлеш), № 78 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 19 (I өлеш), № 79 (I өлеш); 2020, № 51 (I өлеш), № 57 (I өлеш), № 77 (I өлеш), № 94 (I өлеш); 2021, № 20 (I өлеш) гамәлдә булуын 2022 елның 1 гыйнварына кадәр туктатып торырга.

**3 статья**

1. Әлеге Закон, бу статьяда үз көченә керүнең бүтән сроклары каралган нигезләмәләреннән тыш, рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 8 пункты, 10 пунктының «а» пункчасындагы өченче һәм дүртенче абзацлары, 11 пункты, 12 пунктының «а» пунктчасы, 13 пункты 2022 елның 1 гыйнварыннан үз көчләренә керә.

3. Татарстан Республикасы Бюджет кодексының $44^{4}$, $44^{5}$, $44^{6}$, $60^{1}$ статьялары нигезләмәләре (әлеге Закон редакциясендә), 2022 елга, 2023 һәм 2024 еллар план чорына бюджетлардан башлап, Татарстан Республикасы бюджет системасы бюджетларын төзегәндә һәм үтәгәндә барлыкка килә торган хокук мөнәсәбәтләренә карата кулланыла.

Татарстан Республикасы
Президенты Р.Н. Миңнеханов

Казан, Кремль
2021 ел, 30 сентябрь
№ 65-ТРЗ